**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 ноябрендәге 4171 номерлы карары**

**Совет районының Аргамак урамындагы территорияне**
**ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Беренчел документларны әзерләү үзәге» акционерлык җәмгыяте гаризасы буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьялары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 21 гыйнварындагы 296 номерлы карары белән расланган «Офицерлар поселогы» территориясен планлаштыру проекты, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 15 маендагы 1512 номерлы «Совет районының Аргамак урамында территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары нигезендә, 2025 елның 11 сентябреннән алып 2025 елның 25 сентябренә кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне исәпкә алып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Совет районының Аргамак урамындагы территорияне ызанлау проектын әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.

1.2. әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга;

1.3. әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, Казан

шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.4. әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

2. Гражданин А.Н.Зариповка, Г.Р.Шәрәповага, С.Н.Мотыйгуллинага **тәкъдим итәм**:

2.1. шартлы билгеләре ЗУ1 һәм ЗУ2 булган җир кишәрлекләренә дәүләт кадастр исәбе үткәрү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. шартлы билгеләре ЗУ3 һәм ЗУ4 булган ясала торган җир кишәрлекләренә карата җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә кую һәм муниципаль милек хокукын теркәү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә;

2.3. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү өчен әлеге карар кушымтасы нигезендә тиешле документларны тапшырырга;

2.4. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлекләренең кадастр номерлары турында мәгълүмат бирергә;

2.5. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

2.5.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмаларның аларга тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

2.5.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

2.5.3. җир кишәрлекләрендә үсә торган яшел үсентеләрнең сакланышын тәэмин итәргә;

2.5.4. яшел үсентеләрне бетергәндә һәм (яки) күчереп утыртканда, Казан шәһәре Думасының 2006 елның 8 июнендәге 2-9 номерлы «Шәһәрне яшелләндерү турында»гы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләр утырту, аларны карап тоту һәм саклау кагыйдәләре таләпләрен үтәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка **йөклим**.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы**
**урынбасар** **И.В.Куляжев**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 26 ноябрендәге
4171 номерлы карары белән
расланды

**Совет районының  Аргамак урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән территорияне ызанлау проекты турындагы нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге,  кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I.  Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Территорияне ызанлау проекты белән муниципаль милектә булган 16:50:270101:3294, 16:50:270101:3293 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен, шәхси милектә булган 16:50:270101:2452, 16:50:270101:3281 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү юлы белән җир кишәрлекләре ясау каралган.

Җир кишәрлеген яңадан бүлү бер-берсенә кереп урнашуны булдырмас өчен планлаштыру структурасы элементы чикләрендә җир кишәрлеге ясау максатыннан башкарыла.

Шулай ук территорияне ызанлау проекты белән гомуми файдалану территориясе чикләрен билгеләү максатыннан кызыл линияләр билгеләү

каралган. Кызыл линияләр ясала торган җир кишәрлекләре чикләре буйлап урнаштырыла.

ЗУ1 җир кишәрлеге (576 кв.м), ЗУ2 җир кишәрлеге (432 кв.м) арта торган кишәрлек аз үлчәмле булып тормый, шул ук вакытта мөстәкыйль әһәмияткә дә ия түгел, чөнки ул аз үлчәмле, мөстәкыйль әһәмияткә дә ия булмаган аерымланган ике өлештән тора, җир кишәрлекләре конфигурациясе төзелеш эшләрен башкарырга ирек бирми.

Беренчел җир кишәрлекләре турында мәгълүмат 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 таблица

| **Беренчел җир кишәрлеге номеры** | **Беренчел җир кишәрлегенең милек формасы** | **Беренчел җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре** |
|---|---|---|
| 16:50:270101:3294 | Муниципаль | Чокыр |
| 16:50:270101:3293 | Муниципаль | Чокыр |
| 16:50:270101:2452 | Шәхси | Шәхси торак төзелеше өчен |
| 16:50:270101:3281 | Шәхси | Шәхси торак төзелеше өчен |

Беренчел җир кишәрлекләренең төгәлләштерелгән чикләре һәм мәйданы бар.

Ясала торган җир кишәрлекләре турында мәгълүмат 2 нче таблицада күрсәтелгән.

2 таблица

| **Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе** | **Ясала торган җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Ясалу ысулы** |
|---|---|---|
| ЗУ1 | 1432 | Шәхси милектәге җир кишәрлекләрен, муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү |
| ЗУ2 | 2071 | |
| ЗУ3 | 203 | |
| ЗУ4 | 268 | |

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгәнчә, алардан җир кишәрлекләре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре

дип танылa. Шулай итеп, шартлы билгеләре ЗУ1 һәм ЗУ2 булган җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен 16:50:270101:3281 һәм 16:50:270101:2452 кадастр номерлы җир кишәрлекләре төренә ярашлы итеп – шәхси торак төзелеше дип, ә шартлы билгеләре ЗУ3 һәм ЗУ4 булган 16:50:270101:3294 һәм 16:50:270101:3293 җир кишәрлекләренең төре буенча чокыр дип билгеләргә кирәк.


Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә ясала торган җир кишәрлеге Ж1 территориаль зонасында – шәхси һәм блоклы торак төзелеше зонасында урнашкан.

Ясалган җир кишәрлеге түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләре салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген (әлеге таләпләр мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм мәгариф (гомуми һәм махсуслаштырылган белем бирү) оешмаларына, массакүләм спорт белән шөгыльләнә торган спорт оешмаларына һәм корылмаларына, медицина оешмаларына, балалар уйный торган, өлкәннәр ял итә һәм спорт белән шөгыльләнә торган мәйданчыкларга кагылмый);

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, файдаланучы оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.

## II. Территорияне ызанлау сызымы




**Масштаб 1:500**

| ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР: | |
|---|---|
| | территорияне ызанлау проекты чиге |
| 16:50:270101 | кадастр кварталының чиге һәм номеры |
| 16:50:270101:3281 | булган җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | ясала торган җир кишәрлекләре чиге |
| н1 ● | ясала торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары номеры |
| | урам-юл челтәренең билгеләнә торган кызыл линиясе |
| к1 ● | урам-юл челтәре кызыл линиясенең характерлы нокталары номеры |
| | расланган кызыл линияләр чиге |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |